КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 октябрь г.Казань № 832

2025 елда Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2025 елда Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 16 октябрь, 832 нче
карары белән расланды

2025 елда Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 26 декабрендәге 1846 номерлы, «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 Октябрьдәге 1782 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 03 декабрь, 1043 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына (алга таба - Фонд) эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба - субсидия) бирү максатын һәм шартларын билгели.

1.2. Субсидияне финанслау чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 17 июлендәге 1928-б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидия акчалары булып тора.

1.3. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак 2025 елга субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары

билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган).

1.4. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

1.5. Финанслау чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлеше Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыру максатында Фонд эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) бәйле.

1.6. 2025 елда Фондка бирелә торган субсидия күләме 795 710,0 мең сум тәшкил итә.

1.7. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.8. Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан ирешелгән субсидия бирү нәтиҗәсе булып төп капиталга җәлеп ителгән инвестицияләр күләме - кимендә 6 102 млн.сум һәм яңа эш урыннары булдыру - кимендә 50 берәмлек тора.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә 2025 елның 31 декабреннән соңга калмый ирешелергә тиеш.

## 2. Фондка карата таләпләр

2.1. Субсидия бирү өчен гариза бирү көненә (алга таба – гариза) Фонд түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

бердәй салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары юк йә бурыч Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, Фондка карата банкротлык процессы билгеләнмәсә, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты,

шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

бу Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмаса.

2.2. Субсидия алу өчен Фонд Вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда субсидияләр турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң килүче 10 эш көне эчендә Вәкаләтле органга составына түбәндәге документлар кергән гариза тапшыра:

субсидия бирү турында гариза, әлеге Тәртипкә кушымта буенча формага ярашлы, Фонд җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган, субсидиягә ихтыяҗның финанс-икътисади нигезләмәсе белән бергә;

Фонд җитәкчесе яки ул вәкаләтләр биргән зат кул куйган, әлеге Тәртипнең 2.1 пункты таләпләренә туры килүен раслый торган гарантияле хат;

Фонд уставының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе;

заявка бирү датасына кадәр 10 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтә күчермәсен;

Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның 1 нче көненә салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең тәкъдим ителгән мәгънәләре турында Фонд җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган белешмә;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Фонд турында мәгълүмат, Фонд тапшыра торган заявка, субсидия бирүгә бәйле Фонд турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

Барлык документлар да тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең күчермәсе белән) Фонд җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат тарафыннан таныкланырга тиеш.

Әлеге пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларында каралган документларны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.3. Документлар кәгазьдә тапшырыла. Барлык документлар да ачык итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, мөһер белән ныгытылган (булган очракта) һәм Фонд җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш. Гаризаның барлык битләре номерланырга тиеш. Гариза тегелгән һәм Фонд җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер (булган очракта) белән, гаризаның арткы ягында барлык битләр саны күрсәтелеп, расланырга тиеш. Тәкъдим ителгән мәгълүматның дөрес булмавы өчен Фонд Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.

## 3. Фонд тарафыннан җибәрелгән гаризаны карау тәртибе

3.1. Вәкаләтле орган заявканы кергән көнне заявкаларын рекәү журналына теркәп куя, гариза теркәлгән көннән алып өч көн эчендә исәпләнелә торган өч көн эчендә тәкъдим ителгән документларны карый һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.2. Гариза карау өчен Вәкаләтле орган хезмәткәрләре арасыннан гаризаны карау комиссиясе (алга таба – комиссия) булдырыла. Комиссияне формалаштыру тәртибе һәм комиссия турында нигезләмә Вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

Комиссияне булдыру турында боерык түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия сәркатибе, комиссиянең шәхси составы турында мәгълүмат;

комиссиянең вәкаләтләре турында мәгълүмат, аларга түбәндәгеләр керә:

гаризаны карау;

комиссия утырышы беркетмәсен имзалау.

3.3. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карары комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзаларының гомуми санының күпчелеге тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән раслана. Әгәр карар кабул ителгәндә «хуплап» һәм «каршы» тавышлары саны тигез булса, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булачак. Комиссия рәисе булмаганда, комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

3.4. Гаризаны карау түбәндәгеләрне тикшерү өчен башкарыла:

Фондның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

документларның булуы һәм аларның әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе.

3.5. Әгәр гаризаны тулы, җентекле һәм объектив карау максатында Фондтан тәкъдим ителгән документлар һәм мәгълүматлар буенча аңлатмалар алу өчен мәгълүмат һәм документлар алу кирәк булса, Вәкаләтле орган Фондка документлар һәм мәгълүматлар буенча аңлатмалар сорап язма мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауда вәкаләтле орган Фонд тарафыннан документларга һәм мәгүлүматка карата аңлатма бирү срогын билгели, әлеге срок тиешле рәсми сорау урнаштырылган көннән соң килә торган көннән кимендә бер эш көнен тәшкил итәргә тиеш.

Фонд әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән сроклар эчендә әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә соратыла торган мәгълүматны һәм документларны Вәкаләтле органга җибәрә.

Әгәр Фонд әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп соратыла торган документларны һәм мәгълүматны, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән срокта тапшырмаган булса, бу турыда мәгълүмат комиссия утырышы беркетмәсенә кертелә.

3.6. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Фонд тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

Фондның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Фонд тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү;

Әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

Вәкаләтле орган субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көне эчендә Фондка кабул ителгән карар турында язмача хәбәр итә, мондый карар кабул итүнең нигезләрен күрсәтеп.

## 4. Субсидия бирү турында килешү төзү тәртибе

4.1. Субсидия бирү Вәкаләтле орган һәм Фонд арасында төзелә торган субсидия бирү турында килешү (алга таба - килешү) нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасында электрон документ рәвешендә гамәлгә ашырыла һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Вәкаләтле органның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик

хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып тәэмин ителә.

4.2. Килешүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

субсидия күләме;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда субсидияне кире кайтару очраклары;

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында һәм чыгымнарны башкару турында, финанс тәэминаты чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисапны әлеге Тәртипнең 5.1 пунктына туры китереп тәкъдим итү тәртибе һәм сроклары;

Фонд тарафыннан өстәмә хисап бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда);

әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Вәкаләтле органга моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларны килештерү яки килешүнең яңа таләпләре буенча килешенмәгәндә Килешүне өзү турында шарт.

4.3. Фонд кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Фондны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук Фонд бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, Фонд тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

4.4. Вәкаләтле орган, кирәк булганда, Фонд белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

4.5. Бу Тәртипнең 4.1 пунктында күрсәтелгән срокларда Фонд исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә имза куюы тәэмин ителмәгән очракта, Фонд килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

4.6. Фондка, шулай ук Фонд белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

4.7. Вәкаләтле орган Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында Фонд тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондент

счетларына килешү төзелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек чорда акча күчерә.

4.8. Фондның, Фонд белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерүгә һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы.

Фонд акча керүнең һәм тотуның аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

## 5. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру хисабын бирү тәртибе

5.1. Фонд субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында хисапны һәм финанс тәэминаты чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны башкару турында хисапны «Электрон бюджет» системасында, килешүдә билгеләнгән срокларда, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типовой формага кушылган формалар буенча тәкъдим итә.

5.2. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 5.1 пунктында күрсәтелгән Фонд тарафыннан тапшырылган хисапларны аларны алган көннән алып 15 эш көне эчендә тикшерә.

Вәкаләтле орган Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән рәвештә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

5.3. Субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

Фонд тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча да - тулы күләмдә;

субсидия алу өчен Фонд тарафыннан дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр һәм документлар тапшыру - тулы күләмдә;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап, өстәмә хисаплылык (килешүдә мондый билгеләнгәндә) тапшырылмаган очракта – тулы күләмдә;

Фондның субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешмәве - тулы күләмдә;

субсидия чараларын максатсыз куллануны - максатсыз кулланылган субсидия күләмендә.

5.4. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш (Вәкаләтле орган тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Вәкаләтле орган финанс белән тәэмин итү чыганагы хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыруга ихтыяҗ булу яисә күрсәтелгән акчаларны аларга ихтыяҗ булмаганда кире кайтару турында карар кабул итәргә хокуклы.

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Фонд Вәкаләтле органга хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны Фондтан алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча Фондның әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләрен алдагы елларда файдалануга җибәрүгә ихтыяҗ булу яисә булмау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә карар кабул итә.

Вәкаләтле орган Фондның хисап финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләрнең калган өлешләрен җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул иткән очракта, Вәкаләтле орган һәм Фонд арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

5.5. Фонд әлеге Тәртипнең 5.3 һәм 5.4 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срокларын бозганда, Вәкаләтле орган, субсидия кире кайтарылу узган көннән алып, эш көннәрендә исәпләп чыгарыла торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

5.6. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.7. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартларның үтәлүе өчен, тапшырыла торган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге өчен Фонд җаваплы була.

2025 елда Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционер җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрына

______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

______________________________________
җитәкченең (аның вазыйфаларын

______________________________________
башкаручының)

______________________________________
_________ дан (нан)

Заявка
2025 елда Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында

Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше

заводы» акционер җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) ________________ мең сум күләмендә субсидия бирүегезне сорыйм.

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Фонд мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль берәмлекләр территорияләренең гомумроссия классификаторы | |
| 2. | Төп дәүләт теркәү номеры | |
| 3. | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 4. | Салым органында исәпкә куелу сәбәбе датасы һәм коды | |
| 5. | Фонд оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге | |
| 6. | Фонд адресы | |
| 7. | Элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы | |
| 8. | Фонд җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)); | |
| 9. | Субсидия бирү турында килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат | |
| 10. | Җаваплы башкаручы турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, элемтә реквизитлар) | |
| 11. | Банк реквизитлары, шул исәптән исәп-хисап счеты, корреспондент счеты, банк идентификация коды | |

1 нче кушымта
2.

Фонд җитәкчесе __________________ /________________ / ____________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда) «__» ________ 20__ ел

________________________________